ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ с. Верхний Услон КАРАР ______________

«2017-2020 елларга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программаны раслау турында» 2016 елның 04 октябрендәге 1355 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында” 2008 елның 13 октябрендәге 105-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм финанслау булмау сәбәпле, Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 4 октябрендәге 1355 номерлы карары (алга таба - Программа) белән расланган 2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау комплекслы программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Программаның 2 пунктында «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2008 елның 13 октябрендәге 105-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2018 елга Программаны финанслау күләме өлешендә «1954,0 мең сум» сүзләрен «60,0 мең сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. 4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчсе Л.С. Хакимзянов

Әзерләде һәм бастырды
Еремеева А.В.